**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 24 август № 619

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклауның комплексы системасын үстерү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 июнь, 492 нче, 2014 ел, 25 сентябрь, 678 нче, 2014 ел, 9 декабрь, 962 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1090 нчы, 2015 ел, 2 февраль, 54 нче, 2015 ел, 24 апрель, 279 нчы, 2015 ел, 7 август, 576 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклауның комплексы системасын үстерү» ярдәмче программасына (алга таба – ярдәмче программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

ярдәмче программа паспортында «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 6 нчы ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 6 нчы ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 6 нчы ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2013 ел белән чагыштырганда 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре санын 92 процентка кадәр киметергә;<br>судка кадәр тәртиптә җайга салынган кулланучылар бәхәсләренең чагыштырма санын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча алынган консультацияләр санын 112 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар хокукларын яклау турында законнар таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча семинарлар тыңлаган хуҗалык итүче субъектлар санын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләренә кагылышлы материаллар санын 112 процентка кадәр арттырырга;<br>кулланучылар хокукларын яклау турында законнар нигезләре буенча дәресләрдә катнашкан республика белем бирү учреждениеләрендә укучылар санын 113 процентка кадәр арттырырга;<br>аннан соң нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру юлы белән республиканың кулланучылар базарында сатыла торган товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) тикшерүләр һәм аларга экспертизалар үткәрү санын 120 процентка кадәр арттырырга»; |

ярдәмче программага кушымтада:

1.2 пунктта:

1 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшерүдә тотуны камилләштерергә»;

15 – 19 графаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «- | - | - | - | -»; |

2.9 пунктның 15 – 19 графаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «- | - | - | - | -»; |

2.10 пунктның 15 – 19 графаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «2,2 | 2,2 | 2,2 | 2,2 | 2,2»; |

2.11 пунктның 1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Аларга мөнәсәбәттә кулланучыларның әллә ничә тапкыр дәгъвалары булган җитештерүчеләр (сатучылар, үтәүчеләр), товарлар (эшләр, хезмәтләр) турында бердәм республика мәгълүматлар базасын; кулланучылар хокукларын яклау турында законнар тармагында кулланучылар бәхәсләре һәм хокук бозулар буенча суд карарларының һәркемгә ачык банкын булдырырга һәм кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә Татарстан Республикасының мәгълүмат порталын үстерергә»;

3.1 пунктның 8 – 19 графаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «116 | 117 | 118 | 119 | 120 | 0,9 | 1,1 | 1,6 | 1,8 | 1,8 | 1,8 | 1,8». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\619.docx